МИНИСТЕРСТВО ЛЕСНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ УРМАН ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

Тел. (843) 221-37-01, Факс 221-37-37,Е-

ПРИКАЗ | БОЕРЫК

25.07.2018 Казан ш. № 386-осн

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибен раслау турында

«Норматив хокукый актларның һәм норматив хокукый актлар проектларының коррупциягә каршы экспертизасы турында» 2009 елның 17 июлендәге 172-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Норматив хокукый актларның һәм норматив хокукый актлар проектларының коррупциягә каршы экспертизасы турында» 2010 елның 26 февралендәге 96 номерлы карары, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза тәэмин итүнең өстәмә гарантияләре һәм аларны әзерләгәндә җәмәгатьчелек фикерен исәпкә алу турында» 2017 елның 29 июнендәге ПУ-575 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Аерым норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибен раслау турында һәм Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2009 елның 24 декабрендәге 883 номерлы, «Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза тәэмин итүнең өстәмә гарантияләре һәм аларны әзерләгәндә җәмәгатьчелек фикерен исәпкә алу турында» 2017 елның 29 июнендәге ПУ-575 номерлы Указын гамәлгә ашыру чаралары турында» 2017 елның 15 августындагы 580 номерлы Указлары нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыруның кушымтада бирелгән тәртибен расларга.

2. Көчен югалткан дип таныргга:

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында» 2011 елның 19 апрелендәге 154-осн номерлы боерыгын.

3. Юридик бүлеккә дәүләт теркәвенә алу һәм Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматының рәсми сайтында (PRAVO.TATARSTAN.RU) рәсми бастырып чыгару өчен әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

4. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Министр Р.Ә.Кузюров

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының 2018 елның 25.07 № 386-осн боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибе

## I. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1.1. Әлеге Тәртип «Норматив хокукый актларның һәм норматив хокукый актлар проектларының коррупциягә каршы экспертизасы турында» 2009 елның 17 июлендәге 172-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Норматив хокукый актларның һәм норматив хокукый актлар проектларының коррупциягә каршы экспертизасы турында» 2010 елның 26 февралендәге 96 номерлы карары, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза тәэмин итүнең өстәмә гарантияләре һәм аларны әзерләгәндә җәмәгатьчелек фикерен исәпкә алу турында» 2017 елның 29 июнендәге ПУ-575 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Аерым норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибен раслау турында һәм Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2009 елның 24 декабрендәге 883 номерлы, «Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза тәэмин итүнең өстәмә гарантияләре һәм аларны әзерләгәндә җәмәгатьчелек фикерен исәпкә алу турында» 2017 елның 29 июнендәге ПУ-575 номерлы указын гамәлгә ашыру чаралары турында» 2017 елның 15 августындагы 580 номерлы Указлары нигезендә эшләнде, Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының (алга таба – Министрлык) норматив хокукый актларына (алга таба – актлар) һәм норматив хокукый актлары проектларына, Министрлык актларына һәм актлары проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертизаны һәм коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләрен исәпкә алуны да кертеп, коррупциягә каршы экспертиза уздыру процедурасын билгели.

1.2. Актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза аларның хокукый экспертизасы үткәрелгәндә үткәрелә.

Актларга коррупциягә каршы экспертиза аларның кулланылышын мониторинглаганда, шулай ук Министрлыкка Министрлыкның хокукый актларында коррупциячел факторлар булуы турында мәгълүмат ирешкән очракта үткәрелә.

1.3. Коррупциягә каршы экспертизаның максаты булып актларда һәм актларның проектларында коррупциячел факторларны ачыклау һәм алга таба бетерү тора.

1.4. Коррупциягә каршы экспертизага килгән актлар һәм актларның проектлары коррупциягә каршы экспертизага килгән норматив хокукый актларны һәм норматив хокукый актларның проектларын исәпкә алу журналында (алга таба – Журнал) (әлеге Тәртипнең 1 нче кушымтасы) теркәлә.

## II. АКТЛАРГА ҺӘМ АКТЛАРНЫҢ ПРОЕКТЛАРЫНА КОРРУПЦИЯГӘ КАРШЫ ЭКСПЕРТИЗА УЗДЫРУ

2.1. Министрлыкның актларына һәм актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза Министрлыкта Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы боерыгы нигезендә коррупциягә каршы экспертизаны уздыру өчен җаваплы итеп билгеләнгән юридик бүлекнең вазыйфаи заты (алга таба – вазыйфаи зат) тарафыннан уздырыла.

2.2. Актлар һәм актларның проектлары коррупциягә каршы экспертиза уздыру өчен әлеге актны кабул итү инициаторы булган структур бүлекчә җитәкчесе (акт проектын әзерләү өчен җаваплы зат) тарафыннан вазыйфаи затка җибәрелә.

2.3. Актлар һәм актларның проектлары коррупциягә каршы экспертиза уздыру өчен шулай ук Татарстан Республикасы урман хуҗалыгы министры тарафыннан да җибәрелергә мөмкин.

2.4. Коррупциягә каршы экспертиза актны Журналда теркәгән көннән соң ун көнлек чорда уздырыла.

Коррупциягә каршы экспертиза көчен югалткан яки гамәлдән чыгарылган норматив хокукый актларга карата үткәрелми.

2.5. Вазыйфаи зат коррупциягә каршы экспертизаны уздыру процессында, зарурлык булган очракта, коррупциягә каршы экспертизада мәнфәгатьле булган структур бүлекчәләрдән һәм вазыйфаи затлардан өстәмә материалларны яки мәгълүматны сорарга һәм алырга хокуклы. Сорала торган материаллар һәм мәгълүмат вазыйфаи затка гарызнамә алынган вакыттан башлап өч көннән артмаган срокта тапшырылырга тиеш.

2.6. Вазыйфаи зат экспертизага тапшырылган актта (акт проектында) коррупциячел факторларның булуын яисә юклыгын ачыклый.

2.7. Коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләре буенча әлеге Тәртипнең 2 нче кушымтасына туры китерелгән формада бәяләмә төзелә, анда түбәндәге белешмәләр чагылдырыла:

экспертизага тапшырылган актның реквизитлары (акт проектының аталышы);

актның (акт проектының) килгән датасы;

экспертиза уздыру датасы;

экспертиза уздыру нигезе;

актта (акт проектында) коррупциячел факторларның булуы яки юклыгы;

актның (акт проектының) коррупциячел факторларны үз эченә алган конкрет нигезләмәләре;

хокукый нормаларның тәгъбирләнешләрен үзгәртү яки коррупциячеллекне бетерү өчен аерым нормаларны төшереп калдыру буенча тәкъдимнәр.

2.8. Актка (акт проектына) коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләре буенча вазыйфаи зат тарафыннан төзелгән һәм имзаланган бәяләмә әлеге актны (акт проектын) коррупциягә каршы экспертизага җибәргән затка җибәрелә.

## III. КОРРУПЦИЯГӘ КАРШЫ ЭКСПЕРТИЗА БӘЯЛӘМӘСЕНЕҢ ҮТӘЛЕШЕ

3.1. Әгәр коррупциягә каршы экспертизага җибәрелгән актта коррупциячел факторлар ачыкланса, актны кабул итү инициаторы булган структур бүлекчә җитәкчесе бәяләмәне алгач, өч көн эчендә үзгәрешләр кертү яисә коррупциягә каршы экспертиза предметы булган актның көчен югалтуын тану турында норматив хокукый акт проектын әзерләргә һәм коррупциягә каршы экспертиза уздыру өчен вазыйфаи затка җибәрергә тиеш.

Үзгәрешләр кертү турында тапшырылган акт проектында коррупциячел факторлар булмаган очракта, бәяләмә вазыйфаи зат тарафыннан акт кабул итүнең инициаторы булган структур бүлекчә җитәкчесенә җибәрелә һәм акт проекты мәнфәгатьле структур бүлекчәләрнең җитәкчеләре визалары белән бергә имза салу өчен Татарстан Республикасы урман хуҗалыгы министрына (алга таба – Министр) җибәрелә.

3.2. Әгәр экспертизага җибәрелгән акт проектында коррупциячел факторлар булмаса, акт проектын әзерләү өчен җаваплы стурктур бүлекчә җитәкчесе мәнфәгатьле структур бүлекчәләрнең җитәкчеләре визалары белән бергә акт проектын имза салу өчен Министрга җибәрә яисә актның мәнфәгатьле органнарга һәм оешмаларга килештерү өчен җибәрелүен тәэмин итә.

3.3. Әгәр экспертизага җибәрелгән акт проектында коррупциячел факторлар ачыкланса, акт проектын әзерләү өчен җаваплы структур бүлекчә җитәкчесе, бәяләмәне алгач, өч көн эчендә барлык җитешсезлекләрне бетерергә һәм өстәмә эшләнгән акт проектын коррупциягә каршы кабат экспертиза өчен вазыйфаи затка җибәрергә тиеш.

Коррупциягә каршы кабат экспертиза уздыру срогы өч көннән артмый.

Өстәмә эшләнгән акт проектында коррупциячел факторлар булмаган очракта, бәяләмә вазыйфаи зат тарафыннан имзалана һәм акт проекты мәнфәгатьле структур бүлекчәләрнең җитәкчеләре визалары белән бергә имза салу өчен Министрга имза салу өчен җибәрелә.

Өстәмә эшләнгән акт проектында коррупциячел факторлар булган очракта, вазыйфаи зат бәяләмәне Министрга җибәрә. Министр бәяләмәдә булган йомгаклар нигезендә үтәү өчен бәяләмәне структур бүлекчә җитәкчесенә җибәрә.

Структур бүлекчә җитәкчесе өч көн эчендә булган барлык җитешсезлекләрне бетерергә һәм өстәмә эшләнгән акт проектын мәнфәгатьле структур бүлекчәләрнең җитәкчеләре визалары белән бергә имза салу өчен Министрга җибәрә.

3.4. Коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләре Журналда теркәлә.

## IV. АКТЛАРГА ҺӘМ АКТЛАРНЫҢ ПРОЕКТЛАРЫНА КОРРУПЦИЯГӘ КАРШЫ БӘЙСЕЗ ЭКСПЕРТИЗА ҮТКӘРҮ

4.1. Министрлыкта эшләнә торган һәм Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәрендәге http://minleshoz.tatarstan.ru/ рәсми сайтында (алга таба – сайт) урнаштырылган, рәсми рәвештә бастырып чыгарылган Министрлыкның норматив хокукый актлары һәм норматив хокукый актлары проектлары коррупциягә каршы бәйсез экспертиза объектлары булып тора.

4.2. Министрлыкның актлары проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру өчен Министрлыкта актларга һәм актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру өчен җаваплы булган юридик бүлекнең вазыйфаи заты, акт проекты карау өчен юридик бүлеккә җибәрелгән көнгә туры килә торган эш көне дәвамында, эксперт бәяләмәләрен җибәрү өчен адресын (шул исәптән электрон почта адресын), шулай ук коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча бәяләмәләрне кабул итә башлау һәм тәмамлау даталарын күрсәтеп, акт проектын сайтта урнаштыра.

4.3. Сайтта урнаштырылган актларның проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү вакыты кимендә биш эш көне тәшкил итә.

4.4. Актка (акт проектына) коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча Министрлыкка килгән бәяләмә (алга таба – бәяләмә) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының электрон документ әйләнеше буенча бердәм ведомствоара системасында теркәлә һәм Министрлыкның актны (акт проектын) әзерләү өчен җаваплы структур бүлекчәсенә карау өчен җибәрелә.

4.5. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча бәяләмә киңәш итү холкына ия һәм алынган көненнән башлап Министрлык тарафыннан 15 көнлек чорда зарури каралырга тиеш. Карау нәтиҗәләре буенча бәйсез экспертизаны уздырган юридик яки физик затка нигезләнгән җавап җибәрелә, бәяләмәдә ачыкланган коррупциячел факторларны бетерү ысулы турында тәкъдимнәр булмаган очраклардан тыш.

4.6. Актка (акт проектына) коррупциягә каршы бәйсез экспертизаны уздырганда ачыкланган коррупциячел факторлар акт проектын өстәмә эшләү стадиясендә аны әзерләүче тарафыннан бетерелә.

4.7. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза бәяләмәсендә бәян ителгән кисәтүләрне юкка чыгаргач һәм тәкъдимнәрне исәпкә алганнан соң, Министрлыкның акт проектын әзерләү буенча җаваплы булган структур бүлекчәсе

акт проектын, коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча килгән бәяләмәләрне теркәп, яңадан карап тикшерү өчен юридик бүлеккә тапшыра. Кабат карау өч көнлек чорда гамәлгә ашырыла.

4.8. Әгәр актта коррупциячел факторлар ачыкланса, Министрлыкның шушы актны әзерләгән структур бүлекчәсе бәяләмә Министрлыкта теркәлгән көннән башлап өч көнлек чорда актка үзгәрешләр кертү яки аны көчен югалткан дип тану буенча чаралар күрә.

4.9. Министрлыкның актларында һәм Министрлык тарафыннан эшләнгән актларның проектларында коррупциячел факторлар булуы турында таныклый торган коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре белән риза булмаган очракта, Министрлык аталган актларны (актларның проектларын), коррупциягә каршы бәйсез экспертиза бәяләмәсен һәм үзенең ризасызлыгын нигезләгән аңлатма язуын теркәп, законнарда билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына коррупциягә каршы экспертизага җибәрә.

4.10. Әзерләүче үзе тарафыннан әзерләнгән, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон инициативасы тәртибендә Россия Федерациясе Федераль Җыены Дәүләт Думасына кертелә торган федераль законнарның проектларында, Татарстан Республикасы законнары проектларында, Татарстан Республикасы Президенты указлары проектларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары проектларында коррупциячел факторлар булуы турында таныклый торган коррупциягә каршы, шул исәптән бәйсез, экспертиза нәтиҗәләре белән ризалашмаган очракта, әзерләүче күрсәтелгән норматив хокукый актларның проектларын, коррупциягә каршы, шул исәптән бәйсез, экспертиза бәяләмәсен һәм үзенең ризалашмавын нигезләгән аңлатма язуын теркәп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты – Татарстан Республикасы Хөкүмәте Регламентында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына карау өчен кертә.

## V. НОРМАТИВ ХОКУКЫЙ АКТЛАРНЫҢ ПРОЕКТЛАРЫ ХАКЫНДА ИҖТИМАГЫЙ ФИКЕР АЛЫШУ

5.1. Министрлык эшләнә торган норматив хокукый актларның проектлары турында иҗтимагый фикер алышуларны тәэмин итә.

5.2. Иҗтимагый фикер алышу максатларында норматив хокукый актларның проектлары Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының норматив хокукый актлары проектларын, аларга коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру һәм алар хакында иҗтимагый фикер алышу өчен, бердәм төбәк интернет-порталы итеп билгеләнгән Татарстан Республикасы Рәсми порталында (алга таба – Мәгълүмат ресурсы) (http://tatarstan.ru/regulation) урнаштырыла.

5.3. Гражданнарның хокукларына, ирегенә һәм бурычларына кагыла торган норматив хокукый актларның проектлары иҗтимагый фикер алышуны тәэмин итү өчен Мәгълүмат ресурсында урнаштырыла.

5.4. Иҗтимагый фикер алышу максатларында түбәндәгеләр урнаштырылмый:

дәүләт серен тәшкил итә торган белешмәләре яки конфиденциаль холыклы белешмәләре булган норматив хокукый актларның проектлары;

актларны (аларның структур берәмлекләрен) көчен югалткан дип тану турында норматив хокукый актларның проектлары;

аларны әзерләү өчен Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Премьер-министры һәм аның урынбасарлары йөкләмәсендә билгеләнгән срок иҗтимагый фикер алышуның минималь срогыннан азрак (Мәгълүмат ресурсында урнаштыру көненнән соң биш эш көнненән азрак) булган норматив хокукый актларның проектлары;

Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренә яки чыгымнарына йогынты ясый торган норматив хокукый актларның проектлары, Татарстан Республикасы бюджеты үтәлешен тәэмин итүгә бәйле норматив хокукый актларның проектлары;

дәүләт контролен (күзәтчелеген) оештыру һәм гамәлгә ашыру өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларның проектлары;

террорчылыкка, шул исәптән террорчылыкны финанслауга, каршы көрәш чараларын гамәлгә ашырганда дәүләт хакимияте органнарының эшчәнлеген оештыру, тәэмин итү һәм аларның үзара хезмәттәшлек мәсьәләләрен регламентлый торган норматив хокукый актларның проектлары;

мөлкәт белән идарә иткәндә билгеләнә торган бәяләрне (түләү күләмен) билгеләү тәртибен җайга сала торган норматив хокукый актларның проектлары;

Татарстан Республикасы норматив хокукый актларын законнардагы үзгәрешләргә туры китерүгә юнәлдерелгән норматив хокукый актларның проектлары;

суд карарларын, прокурор йогынтысы актларын, контроль-хисап органнары күрсәтмәләрен тормышка ашыру максатларында әзерләнгән норматив хокукый актларның проектлары;

дәүләт функцияләре үтәүнең административ регламентлары һәм дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентлары проектлары;

статистик күзәтү формаларын раслау турында норматив хокукый актларның проектлары;

Татарстан Республикасы норматив хокукый актларының гамәлдә булуын туктатып тору турында норматив хокукый актларның проектлары.

5.5. Иҗтимагый фикер алышуны тәэмин итү өчен норматив хокукый актларның проектлары урнаштырылганда проект әзерләү инициаторы булган структур бүлекчә тәкъдимнәрне һәм кисәтүләрне җибәрү өчен адресны (шул исәптән электрон почта адресын), шулай ук иҗтимагый фикер алышу срогының башлану һәм тәмамлану даталарын күрсәтә.

5.6. Әзерләүче тарафыннан норматив хокукый актларның проектлары хакында иҗтимагый фикер алышу срогы Мәгълүмат ресурсында урнаштырган көненнән башлап биш эш көненнән азрак була алмый.

5.7. Проектны әзерләү инициаторы булган структур бүлекчә тарафыннан иҗтимагый фикер алышу нәтиҗәләре буенча норматив хокукый акт проектын өстәмә эшләү турында карар кабул ителгән очракта, өстәмә эшләнгән норматив хокукый акт проекты шулай ук иҗтимагый фикер алышу максатларында урнаштырыла.

5.8. Норматив хокукый актларның проектларын Мәгълүмат ресурсында урнаштыру Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

5.9. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру срогы, иҗтимагый фикер алышу срогы тәмамланганнан соң 30 көнлек срокта вазыйфаи зат коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру барышында ачыкланган коррупциячел факторлар, иҗтимагый фикер алышу барышында килгән тәкъдимнәр турында җыелма мәгълүматларны, аларны карау нәтиҗәләрен чагылдырып, әлеге Нигезләмәнең 3 нче кушымтасына туры китерелгән формада урнаштыра.

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибенә 1 нче кушымта

Коррупциягә каршы экспертизага килгән норматив хокукый актларны һәм норматив хокукый актларның проектларын исәпкә алу журналы

| N п/п | Актның (акт проекты-ның) экспертизага килү датасы | Актның (акт проектының) аталышы һәм реквизитлары | Нигезе (проектны әзерләүче) | Бәяләмәне төзү датасы | Коррупция-чел норма-ларның булуы/ юклыгы | Бәяләмәне алды | Имза |
| --- | --- | --- | --- | --- | --- | --- | --- |

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибенә 2 нче кушымта

Коррупциягә каршы экспертиза йомгаклары буенча бәяләмә
№ ____________ ____________________

Экспертизага тапшырылган актның (акт проектының) аталышы һәм реквизитлары
____________________________________________________________________
________________________________________________________________________
____
________________________________________________________________________
____

килү датасы ______________________________________________________
экспертиза уздыру датасы___________________________________________
экспертиза уздыру нигезе___________________________________________
анализлана торган актта (акт проектында) коррупциячел факторларның булуы яки юклыгы: ________________________________________________________
________________________________________________________________________
___
актның (акт проектының) коррупциячел нормаларны үз эченә алган конкрет нигезләмәләре
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________

хокукый нормаларның тәгъбирләнешен үзгәртү яки коррупциячеллекне юкка чыгару өчен аерым нормаларны төшереп калдыру буенча тәкъдимнәр
___________________________________________________________________
________________________________________________________________________
___

Коррупциягә каршы экспертизаны
уздырган өчен җаваплы зат

_________ ____________________________
имза Ф.И.А.

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибенә 3 нче кушымта

Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза һәм (яки) проект турында иҗтимагый фикер алышу йомгаклары буенча җыелма мәгълүмат

______________________________________________________________________________
(норматив хокукый актның төре, норматив хокукый актның аталышы)
______________________________________________________________________________

| Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза | | | |
|---|---|---|---|
| № п/п | Эксперт (Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта)/ аккердитация турында күрсәтмә реквизитлары) | Ачыкланган коррупциячел фактор | Әзерләүчедән аңлатмалар |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| Иҗтимагый фикер алышу | | | |
| N п/п | Фикер алышуда катнашучы (Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта) /электрон почта адресы) | Фикер алышуда катнашучының позициясе | Әзерләүчедән аңлатмалар |
| | | | |
| | | | |
| | | | |

| | |
|---|---|
| Килгән тәкъдимнәрнең гомуми саны | |
| Исәпкә алынган тәкъдимнәрнең гомуми саны | |
| Өлешчә исәпкә алынган тәкъдимнәрнең гомуми саны | |
| Исәпкә алынмаган тәкъдимнәрнең гомуми саны | |